МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.01.2023 № 14

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 2 августындагы 757 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 2 августындагы 757 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы

экспертиза уздыру тәртибенә (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 31 октябрендәге 1008 номерлы боерыгы керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары белән» сүзләреннән соң «(алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары)» сүзләрен өстәргә;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив-хокукый актларга карата үткәрелми.»;

9 пунктының өченче абзацында «, Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларыннан тыш, ул административ регламент проекты Министрлык сайтында урнаштырылган көннән алып 15 эш көненнән ким була алмый» сүзләрен төшереп калдырырга.

Министр Э.Ә. Зарипова